МБДОУ «Центр развития ребенка - детский сад №39
«Золотой петушок» г. Альметьевска» /
Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Әлмәт шәһәре
"Баланың сәләтен үстерү үзәге - 39 нчы
"Алтын әтәч" балалар бакчасы "

Педагогик киңәшмә утырышында
каралды һәм кабул ителде
беркетмә № 1 "31" 08 2022 ел
20__

РАСЛЫЙМ:
№ 39 нчы "Алтын әтәч"
балалар бакчасы мөдире
_______ Р.М. Зайнуллина
№ 62 "31" 08 2022 ел

# 2022 -2023 нче уку елына

# рус һәм башка милләт балаларын

# татар теленә өйрәтүче тәрбиячесенең

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Төзеде:
балаларны татар теленә өйрәтүче тәрбияче:
Сунгатуллина
Дамира Дамир кызы

Әлмәт
2022 нче ел

Эчтәлек

I нче бүлек. Максат.
1.0.Аңлатма язуы……………………………………………………………………......3
Норматив – хокукый документлар ………………………………………………......3-4
1.1. Программаның максаты һәм бурычлары…………………………………………..…..4
1.2.Программа принциплары………………………………………………………......4-6

1.3. Милли состав…………………………………………………………………….... 7
1.4. Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр…………………………………………7-8
1.4.1. “Татарча сөйләшәбез” , “Минем өем” проекты, 4 – 5 яшь…………………………..7-8
1.4.2. “Татарча сөйләшәбез” , “Уйный – уйный үсәбез” проекты, 5 – 6 яшь……………..8-9
1.4.3. “Татарча сөйләшәбез” , “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”
проекты, 6 – 7 яшь…………………………………………………………………......…9
1.4.4. Рус төркемнәрендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр…………………………………………………………..……………………9-10
II нче бүлек. Эчтәлек.
2.1. Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү..………………………………………10-11
2.2. Белем бирүдә эш төрләре һәм формалары……………………………………...…. 11
2.3.Комплекслы – тематик план……………………………………………………...12-14
2.3.1. “Татарча сөйләшәбез” , “Минем өем” проекты, 4 – 5 яшь……………...……… 12-14
2.3.2. “Татарча сөйләшәбез”, “Уйный – уйный үсәбез” проекты, 5 – 6 яшь…………...14-17
2.3.3. “Татарча сөйләшәбез” , “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”
проекты, 6 – 7 яшь…………………………………………………………………….....17-20
2.3.4. Ана теленнән комплексслы - тематик планнар. .........................................................20
2.3.5. “Туган телдә сөйләшәбез”, 6 – 7 яшь………………………………………………..20-22
2.3.6. “Туган телдә сөйләшәбез”, 5 – 6 яшь………………………………………………..22-23
2.4. Еллык план…………………………………………………………………..….…23-28
IIIнче бүлек. Оештыру.
3.1. Материаль – техник яктан тәэмин ителеш……………………………………………28-29
3.2. Үстерешле – предметлы тирәлекне оештыру………………………………….........29
3.3. Программалар һәм методик яктан тәэмин ителеш. ………………………………..…29
3.4. Тәрбиячене эш көне бүленеше (Циклограмма)………………………………….29-32
3.5. Белем бирү эшчәнлеге челтәре………………………………………………………....32
3.6. Кулланылган әдәбият……………………...……………………………………......32-33
Кушымта.
Диагностика…………………………………………………………………………….34

## 1.0.Аңлатма язуы.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен, “Минем өем” (4-5 яшь), “Уйный – уйный үсәбез” (5-6 яшь), “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” (6 - 7 яшь) проектларын үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора.

Яңа сүз өйрәткәндә, сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә; төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә; уеннар кулланып (“Ватык телефон”, “Кайтаваз”...) ныгытыла; хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырыла: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин”.

Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә кулланганда “Бу кем?”, “Кем юк?”, “Кәрзиндә нәрсә бар?”, “Нәрсә юк?”, “Серле янчык”, “Әйе-юк”, “Дөресен әйт” дидактик уеннары уйнала.

Аралаша белү күнекмәләре булдырганда “Әйдәгез танышабыз”, “Кунакны сыйла”, “Кибеттә”, “Кафеда”, “Телефоннан сөйләшү”уен ситуацияләре оештырыла.

Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла. Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала.

Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана.

Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр, сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла.

Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм әти-әниләрнең бердәм позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә.

**Норматив – хокукый документлар:**

*Федераль дәрәҗәдә:*

 Федеральный Закон Российской Федерации «Об образовании в РФ» от 29.12.2012 №273

 Приказ Минобрнауки РФ от 17 октября 2013 г. № 1155. Зарегистрирован в Минюсте России 14 ноября 2013 г., регистрационный №30 384 «Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования»

 Приказ Минобрнауки «Об утверждении Порядка разработки примерных основных образовательных программ, проведения их экспертизы и ведения реестра примерных основных образовательных программ» от 28 мая 2014года, № 594

 Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15 мая 2013 г. N 26 г. Москва "Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13 «Санитарно эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций»;

 Приказ Минтруда России №544н от 18 октября 2013 г. Об утверждении профессионального стандарта «Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального общего, основного общего, среднего общего образования) (воспитатель, учитель)». Зарегистрировано в Минюсте 6 декабря 2013, № 30550;
 Приказ от 30 августа 2013 года N 1014 Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам - образовательным программам дошкольного образования;
 Приказ Минтруда России №544н от 18 октября 2013 г. Об утверждении профессионального стандарта «Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального общего, основного общего, среднего общего образования) (воспитатель, учитель)». Зарегистрировано в Минюсте 6 декабря 2013, № 30550;

*Республика дәрәҗәсендә:*
 Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 г. № 68-ЗРТ "Об образовании"
 Закон Республики Татарстан "О языках народов Республики Татарстан" № 1560-XII от 8 июля 1992 года

*Учреждения дәрәҗәсендә:*
 Устав МБДОУ № 39«Золотой петушок»;
 Годовой план работы на текущий учебный год

**1.1.** Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү.

**Бурычлар:** 1. Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшыитеп сөйләшергә өйрәтү;
2. Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
3. Бәйләнешле сөйләм үстерү;
4. Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау(тоемлау) сәләтен булдыру.

**1.1. Максат:** Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Бурычлар:** 1.Сөйләмне аралашу чарасы булараккамилләштерү, файдалана белүкүнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3.Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**1.2. Программа принциплары:**
1. Үстерелешле өйрәтү;
2. Өйрәтү барышында тәрбияләү;
3. Фәннилек;
4. Эзлеклелек һәм системалылык;
5. Аңлаешлылык;
6. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә
алу;
7. Гуманлылык;
8. Күрсәтмәлелек.
Балалар белән эшләү процессында *сүзлек эше* зур урын ала. Сүзлек эше- бәйләнешле сөйләмнигезе. Балалар бакчасында сүзлек эшенең өчбурычы чишелә:
1. Иң беренче чиратта, гомумикулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, алар белән эш-хәрәкәтләрен атау)
сүзлекне баету.

2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.
3. Сүзлекне активлаштыру.
*Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның* төп шарты – тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнеңморфологик, синтаксик ягын, сүзъясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.
*Аваз культурасы тәрбияләү* буенча эш аның сөйләм сулышы, ишетеп кабул итү, артикуляция аппаратын үстерү һ. б. шундый компонентларны үз эченә ала.
*Бәйләнешле сөйләм үстерү* сөйләмнең ике формасын - диалоглы һәм монологлы сөйләмне күздә тота. Диалоглы сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.
Балаларны матур әдәбият һәм халык иҗатыбелән таныштыру– сөйләм үсешенең әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру түбәндәге бурычларны чишкәндә тормышка ашырыла:
1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итүне, күзаллауларны формалаштыру.
2. Әдәби сөйләмне үстерү.
3.Эстетик зәвыкны, әдәби әсәрне кабул итүне үстерү.
Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе булып, бармак уеннары тора.
Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.
Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар, “куян булып сикерәләр”, “кошлар булып очалар”, җим чүплиләр”, “аю кебек алпан- тилпән йөриләр”, “әтәч булып кычкыралар” һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.
УМКда өч белем бирү өлкәсе каралган:
1**. «Танып – белү»** белем бирү өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; ел фасыллары турында белемнәрен тирәнәйтүне үз эченә алган.
2**. «Аралашу»** белем бирү өлкәсе нәниләрдәтуган телгә мәхәббәт тәрбияләү, матур әдәбиятәсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөресәйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыру, диалогик сөйләм чараларын үз эченә алган.
3. **«Матур әдәбият»** белем бирү өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өнди, акыллы, тапкыр булырга киңәш итә, шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр белән таныштыруны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя.

### 1.2. Программа принциплары.

*1.Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.
*2.Интеграция һәм дифференциация принцибы* – һәр сөйләм төренең үзүзенчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләментехник чаралар ярдәмендә (аудио-видеоязмада) тыңлау (аудирование), телүзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;
*3.Күрсәтмәлелекпринцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрлеэшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә- юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

*4.Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*

*5.Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы:* аралашу, танып-белү, социальләштерү, физик культура, сәламәтлек, хезмәт, иминлек, матур әдәбият, иҗади сәнгать, музыка.

*6.Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

*7.Белем бирүне комплекслы-тематик принципкакорып оештыру;*

*8. Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар телматериалын бик теләп үзләштерәләр.

*9.Белем бирү эшчәнлегенең дидактикпринцибы* - гадидән катлаулыга таба бару.

10. *Индивидуальләштерү принцибы* – телөйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту.Балаларның яшьүзәнчәлекләрен исәпкә алу.

**Татар телен өйрәтүдә кулланыла торганчаралар.**

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностикматериаллар.
2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проектөчен аудиоязмалар, анимационсюжетлар, мультфильмнар).
3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек (таратма һәм –күрсәтмәрәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.
4. Символик, график күрсәтмәлелек(пиктограммалар).
5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)
6. Интерактив уеннар.
7. Эш дәфтәрләре.

**Эш төрләре һәм формалары.**

Программа бурычларын үтәүдә эшформаларының, практик гамәлиалымнарның, чараларның әһәмияте зур.

Төп эш төрләре булып түбәндәгеләртора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчыкбелән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннарөйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармактеатры, битлекләр, костюмнар, театркүрсәтү (әти-әниләргә, башка төркембалаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уены, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## 1.3. Милли (националь) состав

| Группа | Количество детей | Тат. Нац. | Рус. Нац. | Смешанные браки | Другие |
|---|---|---|---|---|---|
| «Дружная семейка» | 25 | 4 | 11 | 7 | 3 |
| «Солнышко» | 27 | 11 | 7 | 7 | 2 |
| «Алые паруса» | 24 | 6 | 8 | 9 | 1 |
| «Домовята» | 21 | 8 | 7 | 5 | 1 |
| «Неваляшка» | 21 | 10 | 4 | 4 | 3 |
| «Семицветик» | 15 | 8 | 3 | 2 | 2 |

## 1.4.Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр

### 1.4.1 . Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)
### “Минем өем” проекты

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз. “Минем өем” проекты темалары (“Гаилә”,“Ашамлыклар”,“Уенчыклар”,“Саннар”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (*әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир. Мә, алма*.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.

*-Бу кем? – Бу әти.*

*-Бу нәрсә? – Бу туп.*

Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.

*-Туп нинди? – Кечкенә.*

*-Машина нинди? – Матур.*

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).

*-Бу нәрсә? – Бу туп.*

*Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*

-Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боерык-биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).*

*-Мә, куян. – Бир куян.*

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.

*Зур машина ал. Тәмле алма бир.*

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.

*Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - Мин Оля. Мин малай - Мин Коля.*

Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү

*Син Коля? – Әйе.*

*Син кыз? – Юк, мин малай.*

Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.
*Син кем? – Мин Коля.*
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар. Өйрәнгән сүзләрне, кыска фразаларны аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти. Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә. Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.
Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша. Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар. Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә. Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә. Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә. Раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес куллана белә.
Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана. Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә. Татар телендә сөйләшү теләге бар.

## 1.4.2. Зурлар төркеме (5-6 яшь)
## “Уйный – уйный үсәбез” проекты

**Лексик минимум** – якынча 45 сүз. “Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар”**,** **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*
Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*
Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.
- *Бу кызыл тәлинкә.*
“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар. Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта 107 сүз кулланып татар телендә аралаша.
“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар”**,** **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана. Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана. Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

## 1.4.3.Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)

## “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты

**Лексик минимум** – якынча 60 сүз. “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”,“Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар. Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар. Үзара һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә. Фигыльләрне урынлы куллана. Җырлар, шигырьләр белә.

## 1.4.4. Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр.

***Икенче кечкенәләр төркеме***

Ел дәверендә өйрәнгән сүзләрне, кыска фразаларны аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти. Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә. Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә. Бер-берсе һәм өлкәннәр белән татар телендә аралаша. Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә. Син кем?Бу кем? Бу нәрсә?Нәрсә эшли?Нинди? сорауларын аңлап, җавап бирә. Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә. Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана. Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә. Татар телендә сөйләшү теләге бар.

***Уртанчылар төркеме***

Сүз байлыгы бар. Үзара һәм зурлар белән татар телендә аралаша. Үзе турында тулы җөмләләр төзеп сөйли белә.Сөйләмендә ягымлы сүзләр,боерыкларны куллана . Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә. Нинди? Нишли?Ничә? соравына дөрес җавап

бирә. Иллюстрацияләргә карап әсәрләрнең исемен атый. Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

***Зурлар төркеме***

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар. Үзара һәм өлкәннәр белән татар телендә актив аралаша. Сүзләрне гомумиләштерә белә.Капма –каршы булган сүзләрне атый. Җырлар, шигырьләр, мәкаль, табышмаклар белә. Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана, үзлектән сорау бирә белә.

***Мәктәпкә әзерлек төркеме***

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә. Диалоглы сөйләмдә ягымлы сүзләрне кулланып аралаша белә.Монологик сойләм күнекмәләре бар. Үзара һәм өлкәннәр белән татар телендә актив аралаша. Сүзләрне гомумиләштерә белә.Капма –каршы булган сүзләрне атый.

Рәсемгә карап, аның эчтәлеген сөйли. Җырлар,шигырьләр,мәкаль,табышмаклар,санамышлар,әкиятләр белә. Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана,үзлектән сорау бирә белә.

## II нче бүлек. Эчтәлек.

### 2.1.Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү.

**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)**

Бу яшьтә баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуда мөстәкыйльлеге үсеш ала. Балалар өлкәннәр белән практик эшләрдә (йомыш үтәү, күмәк уеннар) аралашуны дәвам итү өстенә интеллектуаль аралашуга да омтылалар. Бу күпсанлы сораулар (Нигә?, Ни өчен?, Нәрсә өчен?) бирүдә һәм өлкәннәрдән яңа информация алырга теләүдә күренә. Балаларның сүзлегендә теләктәшлек, кеше хәленә керә белү, кызгану сүзләре барлыкка килә. Яшьтәшләрен үзләренә җәлеп итү өчен балалар аралашуның ситуациясенә карап, интонация, ритм, сүз тизлеген җайлыйлар. Өлкәннәр белән аралашу вакытында сөйләм этикеты кагыйдәләрен үтәп, исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү, юату, кызгану, кеше хәленә керә белү сүзләрен кулланалар. Бу яшьтә баланың сөйләме бәйләнешле һәм эзлекле була.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь)**

Алтынчы яшьтә баланың сөйләм үсешендә мөхим үзгәрешләр барлыкка килә.

Авазларны дөрес әйтү бу яшьтә норма булып тора. Балаларда (чит телгә), татар теленә карата кызыксынулары арта, шул телдә сөйләшергә, җырларга, аудио – видеоязмалар тыңларга, телевизион тапшырулар карарга теләкләре үсә. Балалар сөйләмдә гомумиләштерүче, күпмәгънәле сүзләр, антонимнар, синонимнар куллана башлыйлар. Аларның сүзлеге профессияне, социаль учреждениеләрне аңлатучы сүзләр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына баетыла. Балалар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнеп, мөстәкыйль рәвештә уенлы һәм эшлекле диалоглар төзергә, туры һәм кыек сөйләмне кулланырга өйрәнәләр, тасвирлау һәм хикәяләү монологында геройның хәлен, кәефен, эпитетлар һәм чагыштырулар кулланып, бирергә сәләтле. Балалар үзара кара – каршы сөйләшергә, үзләренә юнәлгән сөйләмне аңларга һәм шулай ук тиешле репликаны кулланып җавап бирергә сәләтлеләр. Бу яшьтәге балалар уен ситуацияләре, проблемалы – эзләнүле уен ситуацилярен барлыкка китереп, күрсәтмә әсбаплар, мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**

Бу яшьтә баланың сөйләме төрле контингет кешеләре (өлкәннәр һәм яшьтәшләре, таныш һәм таныш булмаган кешеләр) белән аралашуга мөмкинлек бирә. Балалар авазларны дөрес

әйтү генә түгел, фонемаларны һәм сүзләрне таныйлар. Телнең орфологик системасын үзләштерү аларга исемнәрнең, фигыльләрнең һәм сыйфатларның катлаулы грамматик формаларын төзергә мөмкинлек бирә. Чит телгә карат тотрыклы кызыксыну үсә. Мәгълүмати – аралашу технологияләрен кулланып аралашырга өйрәнәләр, аудио – видеоязмалар, уку – укыту методик комплектларын кулланып предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне һәм сүзтезмәләрне сөйләмдә, аралашуда актив кулланалар. Гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре белән балаларның лексикасы баей, сүз байлыклары арта.. Бу яшьтәге балалар төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзиләр. Татар телендә сөйләшүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белергә, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышалар. Телне аз белүләренә дә карамастан диалогларда катнашырга омтылалар. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары бик еш сөйләмдә катлаулы җөмләләр кулланалар. 6—7 яшьтә баланың сүз байлыгы арта. Диалог төзегәндә бала сорауларга тулы җавап бирергә, үзе сораулар бирергә, әңгәмәдәшен аңларга тырыша. Монологик сөйләм дә актив рәвештә үсә. Балалар эзлекле һәм бәйләнешле итеп сөйли алалар.

**2.2. Белем бирүдә эш төрләре һәм формалары**

**Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.**

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).
3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек (таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.
4. Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)
6. Интерактив уеннар.
7. Эш дәфтәрләре.

**Эш төрләре һәм формалары.**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## 2.3.Татар теленнән комплекслы - тематик планнар

### 2.3.1. Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

### “Минем өем “ проекты

| **Актив сүзләр** | **Сөйләм үрнәге** | **Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм** |
|---|---|---|
| **Гаилә-36 сәгать** | | |
| әти<br>әни | -Бу кем?<br>-Әти(әни, бабай, әби, кыз, малай). | Аудиоязма №1-23<br><br>Дәфтәрдә эш №1-4 |
| малай<br>кыз | -Кем юк?<br>-Әти(әни, бабай, әби, малай, кыз). | Мультфильмнар:<br>1.”Әйдәгез, дуслашыйк”<br>2.”Качышлы уйныйбыз”<br>3.”Шалкан” |
| мин<br>исәнмесез<br>сау булыгыз | -Исәнмесез.<br>-Син кем?<br>-Мин Коля(Оля)<br>-Мин малай.<br>-Сау булыгыз! | |
| исәнме | -Исәнме, әни(әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>-Сау бул, әни (әти, бабай, әби,кыз, малай). | |
| эт<br>песи | -Кем анда?<br>-Мин песи. Мин-Мияу.<br>-Кил монда.<br>-Мин эт. Мин –Акбай.<br>-Кил монда. | |
| әйе<br>юк<br>сау бул | -Син Коля?<br>-Әйе, Коля.<br>-Син малай(кыз)?<br>-Әйе(юк). | |
| әби<br>бабай | -Әти?(әни,бабай,әби,кыз,малай).<br>-Әйе.<br>-Әни?(әти,бабай,әби,кыз,малай).<br>-Юк.<br>-Малай?<br>-Юк,кыз.<br>-Кыз?<br>-Әйе,кыз. | |
| әйбәт | -Хәлләр ничек?<br>-Әйбәт. | |
| **Ашамлыклар-27 сәгать** | | |
| ипи<br><br>алма<br>сөт<br>чәй<br>мә | -Мә,ипи(алма,сөт,чәй).<br>-Рәхмәт,әби.<br><br>-Коля, мә ипи(алма,сөт,чәй)<br>-Рәхмәт. | Аудиоязма<br>№24-39<br><br>Дәфтәрдә эш №5-10<br><br>Мультфильмнар: 1. “Тәмле” |

| | | |
|---|---|---|
| рәхмәт<br>тәмле<br>кил монда<br>утыр<br>аша<br>эч | -Мияу,кил монда. Утыр. (Акбай,Коля, Оля).<br><br>-Оля, кил монда. Мә ипи (алма,сөт,чәй). Ипи(алма,сөт,чәй)тәмле(ме)?<br>-Ипи(алма,сөт,чәй) тәмле. Рәхмәт.<br><br>-Мә, тәмле алма(ипи).<br><br>-Мә, ипи(алма) аша.<br>-Мә, сөт(чәй) эч. | кибетендә”<br>2. “Азат кунак чакыра” |
| **Уенчыклар-44 сәгать** | | |
| бир<br>туп<br><br>зур<br>кечкенә<br><br>матур<br>курчак<br>куян<br>аю<br><br>хәлләр ничек?<br>уйна | -Бу нәрсә?<br>-Туп (курчак,куян,аю).<br><br>-Курчак (туп,куян,аю) бир.<br>-Мә курчак (туп, куян,аю).<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак,куян,туп).<br>-Аю (курчак, туп, куян) нинди?<br>-Аю (курчак,куян,туп) зур (кечкенә,матур,әйбәт).<br><br>-Аю (курчак,куян,туп) нинди?<br>-Аю (курчак,куян,туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт).<br><br>-Аю (курчак,куян,туп)?<br>-Әйе.<br>-Курчак (аю,куян,туп)?<br>-Юк.<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак,куян,туп).<br>-Мә аю (курчак,куян,туп). Уйна.<br><br>-Коля, кил монда. Уйна.<br>-Оля, кил монда. Уйна.<br><br>-Аю (курчак,куян,туп) бир.<br>-Аю (курчак,куян,туп) нинди?<br>-Аю (курчак,куян,туп) зур.<br>-Аю (курчак,куян,туп) кечкенә.<br><br>-Мә, зур аю (курчак,куян,туп).<br>-Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак,куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна).<br><br>-Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.<br><br>-Туп (курчак, куян, аю) нинди? | Аудиоязма №40-53<br><br>Дәфтәрдә эш №11-13<br><br>Мультфильмнар:<br>1.“Паркка сәяхәт”<br>2.”Уенчыклар үпкәләгән”<br>3.”Күңелле уеннар”<br>4.”Акбай һәм Мияу мажаралары” |

| | | |
|---|---|---|
| пычрак<br>чиста<br><br>ю | -Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>-Туп ю.<br>-Туп чиста?<br>-Юк, туп пычрак. (Әйе, туп чиста). Ю-ю-ю-туп (курчак, аю, куян) ю. | |
| | | |
| **Саннар-6 сәгать** | | |
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | -Ничә?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br><br>-Ничә малай?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>-Ничә кыз?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br><br>-Өч?<br>-Юк.<br>-Ике?<br>-Әйе.<br><br>-Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Дәфтәрдә эш №14<br>Мультфильм<br>1.”Уйный-уйный саныйбыз” |
| **Кабатлау-20 сәгать** | | |
| | | Аудиоязма №25<br>Дәфтәрдә эш №61-64<br>Мультфильм:<br>1.”Күңелле ял итәбез” |

**2.3.2. Зурлар төркеме (5-6 яшь)**
**“Уйный – уйный үсәбез” проекты**

| **АКТИВ СҮЗЛӘР** | **СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ** | **АУДИОЯЗМА ЭШ ДӘФТӘРЕ МУЛЬТФИЛЬМ** |
|---|---|---|
| **КАБАТЛАУ - 6 СӘГАТЬ** | | |
| | «Минем өем» проекты буенча | Аудиоязма №1<br>Дәфтәрдә эш №1<br>Мультфильм<br>«Шалкан» |
| **ЯШЕЛЧӘЛӘР - 56 СӘГАТЬ** | | |
| кишер<br><br><br><br>баллы<br>ничә<br><br>суган<br>бәрәңге | -Бу нәрсә?<br>-Кишер.<br>-Мә кишер.<br><br>-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>-Мә зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>-Рәхмәт. | Аудиоязма №2-24<br><br>Дәфтәрдә эш №2-6<br><br>Мультфильмнар:<br>1. «Баллы кишер»<br>2. «Уйный- уйный эшлибез»<br>3.«Юл маҗаралары» |

| | | |
|---|---|---|
| кыяр<br>кәбестә<br>нинди<br><br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз<br>ун<br><br>кызыл<br>сары<br>яшел<br><br>нәрсә кирәк? | -Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак).<br><br>Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>-Мә, кишер (алма) аша. Баллы?<br>-Әйе, баллы. Рәхмәт.<br><br>-Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br><br>-Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br><br>-Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>-Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>-Сау бул, Коля.<br><br>-Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br><br>-Бу туп.<br>-Туп (алма) нинди?<br>-Туп (алма) сары (кызыл, яшел).<br><br>-Нинди туп (алма) юк?<br>-Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк.<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>-Кирәк.<br><br>-Коля, нәрсә кирәк?<br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) кирәк.<br>-Нинди кыяр?<br>-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br><br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br>-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) ю.<br><br>-Оля кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) юа. | 4. «Кем эшләми, шул ашамый» |

| | | |
|---|---|---|
| юа | | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 15 СӘГАТЬ** | | |
| аш<br>ботка | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй).<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк.<br>-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, бәрәңге, кәбестә, кыяр) аша (эч).<br>-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле. | Аудиоязма №25-29<br><br>Дәфтәрдә эш №7,8<br><br>Мультфильм: «Аш бүлмәсе» |
| **САВЫТ – САБА – 12СӘГАТЬ** | | |
| кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр | -Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-(1-10) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, (1-10) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр) кашык (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30-37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Мультфильмнар:<br>1. «Өч аю»<br>2. «Чисталыкта-матурлык» |
| **КИЕМНӘР – 18 СӘГАТЬ** | | |
| күлмәк<br>чалбар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ки<br>сал<br><br><br>йокла | Яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br><br>Чиста күлмәк (чалбар).<br>Матур күлмәк (чалбар).<br><br>Күлмәк (чалбар) юк.<br><br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Нинди күлмәк (чалбар)?<br>-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>-Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br><br>-Курчак, күлмәк (чалбар) ки (сал).<br><br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Мә, күлмәк (чалбар).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, күлмәк (чалбар) ки (сал).<br><br>-Курчак, йокла | Аудиоязма №38-43<br><br>Дәфтәрдә эш №11, 12<br><br>Мультфильм:<br>1. «Киемнәр кибетендә»<br>2. «Шаян уенчыклар» |
| **ШӘХСИ ГИГИЕНА – 6 СӘГАТЬ** | | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | -Хәерле көн.<br>-Мә су, бит (кул) ю.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br><br>-Бит (кул) чиста. | Аудиоязма №43, 44-48<br>Эш дәфтәре №13, 14<br><br>Мультфильм:<br>1. «Ни өчен киемнәр |

| | | |
|---|---|---|
| | -Әйе, бит (кул) чиста. | югалган?» |
| **ӨЙ ҖИҺАЗЛАРЫ – 6 СӘГАТЬ** | | |
| өстәл<br>урындык<br>карават | -Зур (кечкенә) урындык (өстәл, карават).<br><br>-Зур аю, мә зур урындык (өстәл, карават).<br>-Кечкенә аю, мә кечкенә урындык (өстәл, карават).<br>-Нәрсә кирәк?<br>-Урындык (өстәл, карават) кирәк.<br>-Нинди урындык?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) урындык.<br>-Мә, зур урындык.<br>-Рәхмәт. | Аудиоязма №49<br><br>Эш дәфтәре №15<br><br>Мультфильм:<br>«Маша һәм өч аю» |
| **БӘЙРӘМ «ТУГАН КӨН» 12 СӘГАТЬ** | | |
| яратам<br><br><br><br><br><br><br>бар | -Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br><br>-Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br><br>-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.<br><br>-Нәрсә бар?<br>-Туп (курчак) бар.<br>-Нәрсә юк?<br>-Туп (курчак) юк.<br>*Бар, юк* сүзләрен кулланып, «Гаилә», «Яшелчә», «Уенчыклар» темаларын кабатлау.<br>Диалогларны кабатлау.<br>«Кибетле» уеннары. | Аудиоязма №50-60<br><br>Эш дәфтәре №16-19<br><br>Мультфильмнар: 1. «Туган көн»<br>2. «Кем нәрсә ярата?» |
| **БӘЙРӘМ «САБАНТУЙ» - 36СӘГАТЬ** | | |
| | Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.<br>«Гаилә», «Яшелчә», «Уенчыклар» темаларын кабатлау.<br>«Кибетле» уеннары. | Аудиоязма №61-63<br><br>Мультфильм:<br>«Сабантуй бәйрәме» |

**2.3.3.Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**
**“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты**

| Актив сүзләр | Сөйләм үрнәге | Аудиоязма<br>Эш дәфтзре мультфильм |
|---|---|---|
| син кем?<br>хәерле көн<br><br><br><br>тычкан<br><br><br><br>бу кем? | <br>-Хәерле көн, Даша(Егор)!<br>-Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби)!<br><br><br><br><br><br><br>-Бу-әни(әти, кыз, малай)?<br>-Әйе, әни (әти, кыз, малай...) | Аудиоязма №1, 2<br>Аудиоязма №3, 5<br>Дәфтәрдә эш №1<br>Мультфильм “Мияу адашкан”<br><br>Аудиоязма №6<br>Дәфтәрдә эш №2<br><br>Аудиоязма №7,8<br>Дәфтәрдә эш №3 |

| | | |
|---|---|---|
| | | Мультфильм”Аю баласы<br>дөнья белән таныша” |
| бу нәрсә? | -Бу-туп (курчак, машина).<br>-Нинди туп?<br>-Кечкенә (зур, матур, чиста,...) | Аудиоязма №9,10<br>Дәфтәрдә эш№4 |
| нишли?<br>йоклый<br>утыра | -Песи нишли?<br>-Песи йоклый.<br>-Әни нишли?<br>-Әни утыра. | Аудиоязма №11<br>Мультфильм”Батыр Мияу<br>һәм куркак Куянкай”<br><br>Аудиоязма №12<br>Дәфтәрдә эш №5 |
| ашый, эчә | -Егор нишли?<br>-Егор ашый(эчә). | Аудиоязма №13,14 |
| нишлисең?<br>ашыйм, эчәм | -Мияу, нишлисең?<br>-Ашыйм.<br>-Акбай, нишлисең?<br>-Эчәм. | Мультфильм”Тату гаилә”<br>Аудиоязма №15<br>Аудиоязма №16-18 |
| уйный,<br>уйныйм<br>утырам | -Даша(Егор), нишлисең?<br>-Уйныйм.<br>-Утырам. | Мультфильм”Юмарт аю”<br>Аудиоязма №19 |
| барам, кая<br>барасың? | -Кая барасың?<br>-Кафега барам. | Аудиоязма №20<br>Дәфтәрдә эш №6 |
| син нишлисең? | -Син нишлисең?<br>-Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм,<br>барам,утырам, йоклыйм). | Мультфильм “Кафега<br>барабыз”<br>Дәфтәрдә эш №7 |
| сикер-сикерәм | Туп, туп,<br>Матур туп,<br>Сикер, сикер,<br>Матур туп. | Аудиоязма №21-24 |
| сикерә, йөгерә,<br>төлке | Куян сикерә (йөгерә).<br>Туп сикерә.<br>Песи сикерә (йөгерә).<br>Төлке сикерә (йөгерә). | Мультфильм “Урманда<br>күңелле уеннар”<br><br>Аудиоязма №25<br>Дәфтәрдә эш №8 |
| йөгер-йөгерәм | -Йөгер! Син нишлисең?<br>-Мин йөгерәм. | Аудиоязма №26-29<br>Мультфильм “Көчлеләр,<br>кыюлар, җитезләр”. |
| чәкчәк,<br>өчпочмак | -Мин чәкчәк ашыйм.<br>-Мин өчпочмак ашыйм. | Аудиоязма №30-32<br>Дәфтәрдә эш №9<br>Мультфильм “Җәнлекләр<br>спорт бәйрәмендә” |
| яшь | -Сиңа ничә яшь?<br>-Алты яшь. | |
| бүре, керпе | | Аудиоязма №33-35 |

| | | |
|---|---|---|
| | -Мин-бүре. Мин зур, матур, чиста. | |
| әтәч, тавык | Әтәч зур, матур. | Аудиоязма №36,37 |
| | | Дәфтәрдә эш №10 |
| | Тавык кечкенә, матур. | Мультфильм «Циркта” |
| үрдәк | | |
| | | Аудиоязма №38,39 |
| | -Син нәрсә? | Дәфтәрдә эш №11 |
| | -Мин үрдәк. | Аудиоязма №40,41 |
| чана | | Дәфтәрдә эш №12 |
| шуа | | Мультфильм “Шаян |
| шуам | Куян чана шуа. | кошлар” |
| | Мин чана шуам. | Аудиоязма №42,43 |
| | | Аудиоязма №44 |
| бие, | | Дәфтәрдә эш №13 |
| бии | | Мультфильм “Урманда зур |
| биим | -Аю, әйдә, бие! | концерт” |
| | | Аудиоязма №45-48 |
| | | Дәфтәрдә эш №14 |
| ак, кара | | |
| | -Даша кызыл шар ярата? | Аудиоязма №49-51 |
| | -Юк. | |
| | -Даша яшел шар ярата? | Аудиоязма №52 |
| җырла- | Әйе, мин яшел шар яратам. | Мультфильм “Акбай туган |
| җырлыйм | | көнгә барырга әзерләнә” |
| | -Син нишлисең? | Аудиоязма №50,51,53,54 |
| | -Мин җырлыйм. | Дәфтәрдә эш №15 |
| | -Җырлыйбыз. | Мультфильм ”Мияуның |
| | | туган көне” |
| зур рәхмәт | | Аудиоязма №55 |
| | | Дәфтәрдә эш №16 |
| | Зур рәхмәт. | Аудиоязма №56-58 |
| | | Дәфтәрдә эш №17 |
| | | Мультфильм “Урман |
| китап укый | | китапханәсендә” |
| рәсем ясыйм | Кыз китап укый. | Аудиоязма №59-62 |
| мәктәп | | Дәфтәрдә эш №18 |
| | Рәсем ясыйм-алма ясыйм. | Мультфильм “Уйный-уйный |
| | | укыйбыз” |
| | Мәктәп. | Аудиоязма №63-67 |
| укыйм | | Аудиоязма №68 |
| | -Кем укый? | |
| | -Мин укыйм. | Аудиоязма №69,70 |
| | | Дәфтәрдә эш №19 |
| | | Мультфильм “Урман |
| | | мәктәбендә” |
| | Бик тәмле. | |
| дәфтәр | | |

| | | |
|---|---|---|
| | -Бу нәрсә?<br>-Дәфтәр.<br>-Нинди дәфтәр?<br>-Зур (матур, кечкенә, чиста), ак (кара, кызыл, яшел, зәңгәр, сары) дәфтәр.<br>-Ничә дәфтәр?<br>-Алты (1-10) дәфтәр.<br><br>Терем, терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши,<br>Теремкәйдә куян яши,<br>Теремкәйдә бүре яши,<br>Теремкәйдә төлке яши,<br>Теремкәйдә аю яши.-<br>Алар бик дус.<br><br>-Кәҗә кая?<br>-Әнә кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br><br>-Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>-Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br>-Мә, кәҗә, ботка аша.<br>-Юк, мин кәбестә яратам. Кәбестә тәмле. | Аудиоязма №71<br><br>Мультфильм “Теремкәй”<br><br>Аудиоязма №72<br><br>Мультфильм “Кем нәрсә ярата?”<br><br>Аудиоязма №73<br><br>Аудиоязма №74-76<br>Дәфтәрдә эш №20<br><br>Аудиоязма №77,78 |

**2.3.4.Ана теленнән комплекслы - тематик планнар**
**2.3.5. Туган телдә сөйләшәбез**

**Комплекслы тематик план**
**Мәктәпкә әзерлек төркеме**

| **Проект темалары** | **Эшчәнлек төрләре** | **Эшчәнлек саны** |
|---|---|---|
| **1. Әйдәгез,танышабыз!** | Әйдәгез, танышабыз | 1 |
| **2. Тату гаилә** | Минем өем | 1 |
| **3. Абдулла Алиш иҗаты** | А. Алиш иҗаты белән танышу. | 1 |
| **4. Алтын көз** | Алтын көз | 1 |
| **5. Көзге байлык** | Яшелчәләр | 2 |
| **6. Көз күчтәнәчләре** | Җиләк-җимешләр | 1 |
| **7. Икмәк – яшәү терәге** | “Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә” | 1 |
| **8. Ашамлыклар** | Ашамлыклар | 1 |
| **9. Савыт-саба** | Савыт-саба | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| **10. Өй җиһазлары** | Минем өем, өй җиһазлары | 1 |
| **11. Милли киемнәр** | Әбиемнең серле сандыгы | 1 |
| **12. Минем туган җирем** | Татарстан буйлап сәяхәт | 1 |
| **13. Башкалам - Казан** | Башкалам - Казан | 1 |
| **14. Кыргый хайваннар** | Кыргый хайваннар | 2 |
| **15. Ишек алдында** | Йорт кошлары | 1 |
| **16. Кыш килде** | Кыш килде | 1 |
| **17. Кышкы уеннар** | Кышкы уеннар | 1 |
| **18. Кыш. Кышкы уеннар** | Кыш. Кышкы уеннар | 2 |
| **19. Кышлаучы кошлар** | Кышлаучы кошлар | 2 |
| **20. Киемнәр** | Киемнәр | 1 |
| **21. Муса Җәлил** | Муса Җәлил | 2 |
| **22. И туган тел, и матур тел...** | Бөтендөнья телләр көне | 1 |
| **23. Безнең шәһәр** | Безнең шәһәр | 2 |
| **24. Ямьле яз** | Ямьле яз | 2 |
| **25. Әкияттә кунакта** | Әкияттә кунакта | 1 |
| **26. Күчмә кошлар** | Күчмә кошлар | 2 |
| **27. Белем иленә сәяхәт** | Белем иленә сәяхәт | 2 |
| **28. Мәктәп** | Без мәктәпкә барабыз | 2 |
| **29. Урман-безнең байлыгыбыз** | Урманда | 1 |
| **30. Габдулла Тукай** | Г. Тукай әкиятләренә сәяхәт | 1 |
